**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет**
**Азнакаевского**
**муниципального района**

ул. Ленина, д..22, г. Азнакаево, 423330
Тел./факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы**
**башкарма комитеты**

Ленин урамы, 22 йорт, Азнакай шәһәре, 423330
Тел./ факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

**«25» март 2022 ел** **№ 97**

Азнакай муниципаль районы башкарма комитетының 2020 елның 01 октябрендәге 256 нчы «Архитектура һәм шәһәр төзелеше өлкәсендә муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентлары турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында (2021 елның 03 февралендәге 15 нче, 2021 елның 09 мартындага 45 нче, 2021 елның 28 июлендәге 170 нче, 2021 елның 20 сентябрендәге 205 нче, 2021 елның 15 декабрендәге 324 нче номерлы карарлар редакциясендә)

Азнакай муниципаль районы башкарма комитетының 2020 елның 01 октябрендәге 256 нчы карарына Азнакай шәһәр прокуратурасының 2022 елның 04 мартындагы №02-08-02/2022 протесты нигезендә Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 51, 55 статьялары нигезендә, карар бирә:

1. Азнакай муниципаль районы башкарма комитетының 2020 елның 01 октябрендәге 256 нчы карары белән расланган төзелешкә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә (2021 елның 03 февралендәге 15 нче , 2021 елның 09 мартындага 45 нче, 2021 елның 28 июлендәге 170 нче, 2021 елның 20 сентябрендәге 205 нче, 2021 елның 15 декабрендәге 324 нче номерлы карарлар редакциясендә)

1.1. 1.5 пунктта:

1.1.1. 2 пунктчага «(күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә өлешле төзелештә катнашучыларның акчаларын җәлеп итеп, индивидуаль торак төзелеше объектларын төзүдән тыш)» сүзләрен өстәргә;

1.1.2. 6 пунктчага «шул исәптән Россия Федерациясе ГрК 52 статьясындагы 11 өлешендә күрсәтелгән очракта» сүзләрен өстәргә;

1.1.3. 9 пунктчада «0,6 мегапаскаль» сүзләрен «1,2 мегапаскаль» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. 2.5.1 пунктның 7 пунктчасында «блокланган төзелеш йортларының берсен яисә аның күчермәсен реконструкцияләгән очракта (электрон форманы тутырганда)» сүзләрен өстәргә.

2. Азнакай муниципаль районы башкарма комитетының 2020 елның 01 октябрендәге 256 нчы номерлы карары белән расланган, Объектны эксплуатациягә кертүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә (2021елның 03 февралендәге 15 нче, 2021 елның 09 мартындагы 45 нче, 2021 елның 28 июлендәге 170 нче, 2021 елның 20 сентябрендәге 205 нче, 2021 елның 15 декабрендәге 324 нче карралар редакциясендә):

2.1. 2.5.1 пункттагы 6 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) төзелгән, реконструкцияләнгән капиталь төзелеш объектын инженер-техник тәэмин итү челтәрләренә тоташтыру (технологик тоташтыру) турында акт (бу объектны тоташтыру (технологик тоташтыру) проект документациясе тарафыннан каралган очракта);»;

2.2. 2.6.1 пункттагы 5 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5) төзелгән, реконструкцияләнгән капиталь төзелеш объектын инженер-техник тәэмин итү челтәрләренә тоташтыру (технологик тоташтыру) турында акт (әгәр бу объектны тоташтыру (технологик тоташтыру) проект документлары белән каралган булса) инженер-техник тәэмин итү челтәрләрен эксплуатацияләүче муниципаль берәмлек булган очракта.».

3. Әлеге карарны "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында" түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмати-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aznakayevo.tatar.ru//.

4. Әлеге карарның үтәлешен Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура буенча урынбасары Р.Р. Ханнановка йөкләргә.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы,
икътисад һәм финанслар буенча
җитәкче урынбасары О.Н.Газизова